Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

# Шөгыль-әңгәмә

## “Тәрбияле бала һәм Р.Фәхреддин”

“Салават күпере”
балалар бакчасы
Татар теле тәрбиячесе
Габидуллина Л.Р.

**Тема:** “Тәрбияле бала” һәм Р.Фәхреддин.
**Максат**:

1. Татар халкының күренкле шәхесе Р.Фәхреддиннең балачагы, эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү
2. “Тәрбияле бала” китабына таянып, мисаллар аша “тәрбия” төшенчәсенең мәгънәсен аңларга ярдәм итү.
3. Халкыбызның бөек улларына ихтирам тәрбияләү.

**Шөгыль барышы:**
Агачларның башын киссәң, төбе кала.
Төпләренә утлар яксаң, көле кала.
Адәмнәрнең җаны шаһит китсә,
Җыры кала, эше кала, эзе кала.

- Балалар, сез татар халкының күренекле шәхесләреннән кемнәрне беләсез?
- *Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш, Р.Батулла, Р.Миңнуллин.*
(*мультимедия аша күренекле шәхесләрнең фотолары, рәсемнәре күрсәтелә һәм слайд азагында Ризаэддин Фәхреддиннең фотосы чыга*).
- Шушы мәшһүр кешеләребез арасында сезгә әле таныш булмаган галим, педагог, журналист, тарихчы, язучы Р.Фәхреддин дә бар (*балаларга таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсе аңлату*).

Р.Фәхреддин хәзерге Әлмәт районына кергән Кичүчат авылында, моннан бик күп еллар элек гаҗәеп салкын гыйнвар аенда, мулла гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Башлангыч белемне дә ул шушы авылда ала. Яхшы укый, башка балаларга караганда белемне тизрәк үзләштерә, бик тырыш, кызыксынучан булып үсә, зурларны хөрмәт итә, бик тәрбияле бала була.
- Балалар, Р.Фәхреддиннең фотосына карап сез аның турында нәрсә әйтә аласыз, сезнеңчә ул нинди кеше булган?
- *Акыллы, кырыс, таләпчән, уйчан.*
- Әйе, Р.Фәхреддин чыннан да әлеге сыйфатларның барысына да ия.

(*экранда Р.Фәхреддиннең “Тәрбияле бала” китабыннан өзек язылган. Өзекне укыйм һәм эчтәлеген аңлатам*).

“... Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык вә ахирәттә йөзгә аклык китерер...”
- Балалар, без нинди балага “тәрбияле бала” дип әйтә алабыз?
- *Ул матур итеп исәнләшә, ягымлы итеп сөйләшә, өлкәннәрне һәм кечкенәләрне хөрмәт итә, кешеләр сөйләшкәндә бүлдерми, сорамыйча алмый, алган уенчыкларын урынына куя һәм башкалар.*
- Тәрбияле – ул яхшы, намуслы, мәрхәмәтле дигәнне аңлата.

Р.Фәхреддин бөтен гомер буе балалар белемле, сәламәт, тәрбияле, үз телләрен яратсыннар дип тырыша, шуңа багышлап бик күп китаплар яза. Менә шуларның берсе “Тәрбияле бала” китабы.
(*балаларга күрсәтәм һәм экрандагы өзекнең әлеге китаптан алынганын әйтәм*).

- Балалар, сез тәрбиягә багышланган нинди мәкальләр беләсез?

1. *Үзең яхшы булсаң – кеше дә яхшы булыр.*
2. *Кечегә шәфкать итеп юл бир, олыга хөрмәт итеп кул бир.*
3. *Олылыасаң олыны, олыларлар үзеңне.*
4. *Олкәннәрнең хәлен белеп тор, гомерең озын булыр.*

Мин сезгә каләмнәр һәм ясалып бетмәгән сурәтләр таратам. Сез яхшы кешенең йөзен күз алдыгызга ничек китерсәгәз, рәсемнәрдә шуны ясап күрсәтегез.





- Тәрбияле кешеләр бер-берсенә яхшы теләкләр әйтә белә. Әлеге очракларда нинди теләкләр әйтеп була?

1. *Йокларга ятар алдыннан (хәерле төн, әнием, әтием. Тәмле төшләр сезгә).*
2. *Ашарга утыргач (ашларыгыз тәмле булсын).*
3. *Якыннарыгызның кәефен күтәрәсегез килсә (син бүген бигрәк матур, син минем иң кадерлем).*

- Балалар, кешеләр арасында тәрбиялеләр дә бик күп, тәрбиясезләр дә очрый, кызганычка каршы. Хәзер мин сезгә өзек укыйм, ә сез балаларның кайсысы ныграк ошаганын һәм ни өчен ошаганын әйтерсез:

"Урамнан агач аяклы Сәләхи бабай килә. Лилия ишек алдын себереп тора иде.

- Исәнмесез, бабакай! – диде ул. – Кая барасыз болай ашыгып?
- Исәнме, кызым! – диде Сәләхи бабай.
- Җәмилә әбекәй ни хәлдә?
- Җәмилә әбиегез авырып тора шул, - диде бабай. Менә даруханәгә дару алырга барам, табиб язу биргән иде.
- Рәхим итеп, язуыгызны бирегез, үзем барып килим! – диде Лилия. Мин тизрәк йөрим. Өегезгә кайта торыгыз. Җәмилә әби борчылмасын, сәламәтләнер, Алла боерса, - диде Лилия. Ул тиз генә бабайдан язуны алды да даруханәгә йөгерде.

Каршы йорттан велосипедка атланган малай килеп чыкты.

- Әй син, агач аяк! Юлдан кит әле, күрәсең ич ашыгам! – дип кычкырды ул Сәләхи бабайга".

(педагог балаларга сораулар бирә)

1. Кайсы бала күбрәк ошады һәм ни өчен?
2. Велосипедка атланган малайга сез нәрсә әйтер идегез?
3. Өлкәннәр һәм үзегездән кечеләргә нинди ярдәм күрсәткәнегез бар?

- Ләйсән бүгенге шөгыльгә Ә.Бикчәнтәеваның "Бик рәхмәт, кызларым!" шигырен өйрәнеп килгән. Әйдәгез, шөгылебезне әлеге шигырь белән тәмамлыйк:

*Фәридә, Зөбәйдә,*
*Мәктәпкә баралар.*
*Алар бик акыллы,*
*Тәртипле балалар.*
*Бу кызлар бер сукыр*
*Әбине күрәләр.*
*Тиз генә йөгереп,*
*Янына киләлләр.*
*- Тукта әле, әбекәй,*
*Таптала күрмә син,*
*Җитәклик үзеңне,*
*Ялгызың йөрмә син.*
*Бу сукыр әбине,*
*Җитәкләп кулыннан,*
*Чыгарды ике дус,*
*Трамвай юлыннан.*
*Озатып куйдылар*
*Бик ерак арага.*
*- Бик рәхмәт, кызларым,-*
*Ди әби аларга.*

**Йомгаклау:**

- Балалар, без бүген кем белән таныштык? Р.Фәхреддин кем ул? Ул балаларның нинди кешеләр булып үсүен теләгән?

Минем сезгә теләгем шул: мәшһүр галимебез күререгә теләгәнчә, бөтен яктан да үрнәк балалар булып үсегез!

Кулланган әдәбият исемлеге:

1. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. Татарстан Республикасы Мәгәриф һәм Фән министрлыгы. Казан -2009
2. “Мәгәриф” 2007/10
3. “Ачык дәрес” гыйнвар 2010.